КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 21

Җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 20 гыйнвар, 21 нче
карары белән расланды

Җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели (алга таба – инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту).

2. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затларга, аларның җитәкчеләренә һәм башка вазыйфаи затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, аларның вәкаләтле вәкилләренә (алга таба – шул ук эзлеклелектә юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр) карата гамәлгә ашырыла.

3. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Министрлык Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертларны, Россия Федерациясенең илкүләм аккретидацияләү системасында аккредитацияләү турындагы законнары нигезендә аккредитацияләнгән, тикшерелә торган юридик зат, индивидуаль эшмәкәр белән гражданлык-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелүче затның тәэсир ясый торган затлары булып тормаган эксперт оешмаларын билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә хокуклы.

4. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту предметы булып юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законның 15 статьясы, “Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы” 2007 ел, 8 ноябрь, ФЗ-259 нчы Федераль законның $21^1$ статьясындагы 5 һәм 6 өлешләр белән күздә

тотылган инвалидлар арасыннан пассажирлар йөртүгә һәм аларның багажын ташуга карата таләпләрне (алга таба – таләпләр) үтәү тора.

5. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга, юридик затларны, индивиуаль эшмәкәрләрне тикшерүләрне оештыруга һәм үткәрүгә бәйле булган мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында" 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон (алга таба – ФЗ-294 нче Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

6. Министрлыкның инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада билгеләнә.

7. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда Министрлыкның вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары, экспертлар, эксперт оешмалары, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр белән үзара хезмәттәшлек итә.

8. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

2) хезмәт таныклыгын һәм министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен күрсәтеп, юридик зат, индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда файдалана торган территорияләрне, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, урыннарны, җиһазны, транспорт чараларын тикшерергә һәм аларда булырга;

3) тикшерү үткәрү турында боерык чыкканнан соң юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны сорарга, дөрес булмаган мәгълүматлар булуны ачыклаган очракта, документлар нигезендә тикшерү үткәрү барышында юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр адресына мотивлаштырылган сораулар җибәрергә, күчмә тикшерү үткәргәндә юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән, әгәр күчмә тикшерү үткәргәнгә кадәр документлар нигезендә тикшерү үткәрелмәсә, тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документларны алырга;

4) күчмә тикшерү үткәрүгә юридик затларны, индивидуаль эшмәкәрләрне, экспертларны, тикшерелә торган юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр белән гражданлык-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелүче затның тәэсир ясый торган затлары булып тормаган эксперт оешмаларын җәлеп итәргә;

5) юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән таләпләрне бозу факты буенча аңлатмалар алырга.

9. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тоту юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә план нигезендә һәм планнан тыш, документлар буенча һәм күчмә тикшерүләр үткәрүне оештыру һәм үткәрү, таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү, ачыкланган бозулар нәтиҗәләрен кисәтү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган чаралар кабул итү ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

10. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда административ процедуралар вакытлары һәм эзлеклелеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары нигезендә Министрлык тарафыннан эшләнә һәм раслана торган административ регламент белән билгеләнә.

11. Юридик затларны, индивидуаль эшмәкәрләрне тикшергәндә инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар ФЗ-294 нче Федераль законның 15 һәм 18 статьялары белән билгеләнгән чикләүләрне үтәргә һәм йөкләмәләрне башкарырга, шулай ук үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап бирергә тиеш.

12. Тикшерүләр үткәргәндә юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан таләпләр бозылу ачыкланган очракта, Министрлыкның тикшерү үткәрүче вазыйфаи заты ФЗ-294 нче Федераль законның 17 статьясы белән күздә тотылган вәкаләтләрне тормышка ашыруны гамәлгә ашыра.

13. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

14. Инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда инвалидларга җиңел таксилар белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары
ИСЕМЛЕГЕ

1. Министр.
2. Министр урынбасары.
3. Транспорт идарәсе башлыгы.
4. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгы, төп киңәшчесе, төп консультанты, төп белгече.